ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal..Utz@tatar. ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№1** **30 ноябрь 2021 ел**

Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары белән расланган Уставның 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык ур., 3 нче йорт адресы буенча урнашкан Тынычлык урамы, 3 нче йорт янында 2022 нче елда Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 нче елның 11 нче декаберендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенә керүче Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән гражданнардан 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә Тынычлык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты халык җыенына әзерлек һәм аны үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева